Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр
башкарма комитеты

422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27

тел. 3-15-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
исполнительный комитет
города Арск
422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27

тел. 3-15-25, 3-12-35

# КАРАР

**« 19 » февраль 2021 ел** **№ 17**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 11 августындагы 70 номерлы «Агач һәм куакларны кисүгә, кронлаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, кронлаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кергән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясендәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" Арча шәһәр Советының 18 февраль 2021 ел, №29 карары нигезендә Арча шәһәр башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 11 августындагы 70 номерлы «Агач һәм куакларны кисүгә, кронлаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, кронлаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2 пунктча өстәргә:

«2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына - Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенә салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.».

2) 2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.».

3) 3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге соратулар җибәрә:

- күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү турында (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык белешмәләр булган);

- салым, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычларның булуы (булмавы) турында белешмәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән сорату.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны торак-коммуналь һәм җир мәсьәләләре буенча җитәкче урынбасарына йөкләргә.

Арча шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Ф. Касыймов